**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 № 478

2020 елга гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2020 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2019 елның 18 сентябрендәге 553/пр боерыгы нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районының башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Авыл җирендә яшәүче яшь гаиләләрне һәм яшь белгечләрнең яшәү шартларын яхшырту максатларында «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2014-2020 елларга федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 2020 елга Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 53024 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми порталында һәм Кама Тамагы муниципаль районының http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/rus/ веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары Р.И. Галимовка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин